**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
**III чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**III созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
от 12.08.2020г

**РЕШЕНИЕ**
№47-09

Аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору өлешендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында» 2020 елның 19 мартындагы 670-р номерлы күрсәтмәсенә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 820-р номерлы күрсәтмәсенә таянып, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының муниципаль казнасын тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне (алга таба - муниципаль мөлкәт) арендалау шартнамәләре буенча Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

а) кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән арендаторлар-кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мөрәҗәгать иткән көннән алып җиде эш көне эчендә муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен кичектерүне күздә тоткан өстәмә килешүләр төзү, 2020 елның апрель - июнендә кичектерелгән аренда түләүләрен түләү срогы белән, 2021 елның гыйнварыннан да соңга калмыйча, мондый арендаторлар тәкъдим иткән срокка;

б) Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында арендаторлар - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен әлеге карар үз көченә кергән көннән әлеге пунктның 2 пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә өстәмә килешүләр төзү мөмкинлеге турында мәгълүмат урнаштыру.

2.Түбәндәгеләрне билгеләргә:

а) аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору, Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәлләр режимы кертелгән датага яисә гадәттән тыш хәл кертелгәнчегә кадәр булган кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча алдагы чор өчен аренда түләүләрен түләү буенча үтәлмәгән бурычлары булмаган, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирелә.

б) Әлеге карарның 1 пунктының «а» пунктчасы нигезендә төзелә торган өстәмә килешүләр 2020 елның апрель - июнь айлары өчен аренда түләвен кичектерүне һәм 2020 һәм (яисә) 2021 елларда аренда шартнамәсендә каралган срокларда аны тигез өлешләр белән түләүне, шулай ук аренда шартнамәсен вакытыннан алда өзгәндә кичектерү бирелә торган аренда түләүләре суммасын бер мәртәбә түләүне күздә тотарга тиеш.

3. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына әлеге карарның үтәлеше турында Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына 2020 елның II кварталыннан башлап

хисап кварталыннан соң килүче айның 10 числосыннан да соңга калмыйча мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткерү) көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Актаныш муниципаль районы
Советы Рәисе

Э.Н.Фаттахов